КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 август г.Казань № 736

2018/2019 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 ел, 31 декабрь, 1441 нче карарын үтәү йөзеннән һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:
2018/2019 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планын;
Татарстан Республикасы районнарында һәм шәһәрләрендә гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү, аларны чакыруны оештыру һәм үткәрү мәсьәләләре буенча ведомствоара мониторинг төркеме составын.
2 Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыкларына түбәндәгеләр буенча чаралар күрергә, шулай ук Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына, Татарстан Республикасы территориясендәге оешмалар җитәкчеләренә, эшчәнлекләре Россия Федерациясе территориясендә рөхсәт ителгән иҗтимагый берләшмәләргә чаралар күрүне тәкъдим итәргә:
хәрби хезмәткә чакыру алды яшендәге гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча;
белем бирү оешмаларында, уку-укыту пунктларында, шулай ук хәрби-патриотик, яшьләр һәм балалар берләшмәләрендә гражданнарга хәрби-патриотик тәрбия бирү эшен оештыру буенча;
белем бирү оешмаларының, уку-укыту пунктларының, спорт комплексларының һәм патриотик тәрбия бирү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә

чакыру алдыннан әзерләү үзәкләренең гамәлдәге уку-укыту-матди базасын камилләштерү буенча;

эшләп торучы спорт-гамәли һәм хәрби-техник секцияләр һәм клублар эшләве буенча;

хәрби хезмәткә чакыру алды яшендәге гражданнарга хәрби-патриотик тәрбия бирү эшен оештырганда муниципаль берәмлекләрнең белем бирү оешмалары һәм башка оешмаларының спорт инфраструктурасыннан актив файдалану буенча.

3. Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыкларына, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча) һәм Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) белән берлектә, түбәндәгеләр буенча эшләрне дәвам иттерергә:

белем бирү оешмаларын һәм уку-укыту пунктларын педагогик кадрлар белән комплектлау;

Татарстан Республикасында кадетлар белеме бирүне үстерү.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына башлангыч хәрби исәпкә куйганнан соң профилактика медицина тикшерүләре нәтиҗәләре һәм хәрби хезмәткә чакыру нәтиҗәләре буенча гражданнарга дәвалау-савыктыру чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы белән берлектә, гражданнарга патриотик тәрбия бирү, хәрби хезмәтне үтүгә карата кызыксынуны арттыру, хәрби хезмәткә чакырылучыларны социаль яклау буенча даими рәвештә мәдәни-массакүләм чаралар үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017/2018 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында» 2017 ел, 27 сентябрь, 727 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 29 август, 736 нчы
карары белән расланды

2018/2019 уку елында Татарстан Республикасында
гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар
**ПЛАНЫ**

| Т/с | Чара исеме | Җаваплы үтәүчеләр | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **I. Оештыру чаралары** | | | |
| 1. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018/2019 уку елында хәрби хезмәт нигезләре буенча уку-укыту җыеннарын оештыру һәм үткәрү турындагы боерыгы проектын эшләү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | уку елы дәвамында |
| 2. | Татарстан Республикасының хәрби частьлары һәм муниципаль берәмлекләре арасындагы шефлык элемтәләрен киңәйтү эшләрен үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Регио-наль оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча) | |
| 3. | Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү эшчәнлеген мониторинглау | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасының Региональ оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), «Юнармия» төбәк хәрби-патриотик хәрәкәте (килешү буенча), Республиканская общественная организация ветеранов (инвалидов) «Татарстан Республикасының Ветераннар берлеге» ветераннарның (инвалидларның) республика иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| **II. Хәрби хезмәткә әзерләүне кадрлар белән һәм уку-укыту-методик тәэмин итү** | | | |
| 1. | Республиканың белем бирү оешмаларын тормыш иминлеге нигезләре укытучылары – оештыручылары һәм кадетлар | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Респуб- | даими рәвештә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | тәрбиячеләре белән комплектлау | ликасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | |
| 2. | «Тормыш иминлеге нигезләре» һәм «Тормыш иминлеге» курсларын укыту өчен уку-укыту-методик һәм күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итүдә белем бирү оешмаларына ярдәм күрсәтү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча) | даими рәвештә |
| 3. | Хәрби хезмәткә әзерләү мәсьәләләре буенча конференцияләр һәм семинарлар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Региональ оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| **III. Гражданнарны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләү** | | | |
| 1. | Гражданнарны хәрби хезмәт нигезләре буенча укытуны оештыру | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Респуб- | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | ликасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | |
| 2. | Белем бирү оешмаларының 10 сыйныф укучылары һәм һөнәри белем бирү оешмаларының чыгарылыш алды курслары укучылары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча уку-укыту җыеннары үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең «Казан Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» югары белем бирә торган федераль дәүләт казна хәрби белем бирү учреждениесе (килешү буенча) | 2019 елның май – июне |
| 3. | Хәрби хезмәт нигезләре буенча слетлар, ярышлар, конкурслар, олимпиадалар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Региональ оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татар- | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | стан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча) | |
| **IV. Гражданнарга хәрби-патриотик тәрбия бирү** | | | |
| 1. | Белем бирү оешмаларында «Батырлык дәресләре», Ватан тарихына багышланган сыйныфтан тыш чаралар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Региональ оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 2. | Белем бирү оешмаларында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 74 еллыгына багышланган сугышчан дан музейлары һәм почмаклары смотр-конкурсы үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Региональ оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча) | |
| 3. | Ватанны саклаучылар көненә багышланган массакүләм-оборона һәм спорт эшләре буенча чаралар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Региональ оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 4. | «Хәрби хезмәткә чакырылучы көне» социаль-патриотик акциясен үткәрү | муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комис-сариатының муниципаль берәмлекләр буенча бүлекләре (килешү буенча) | 2018 елның 25 октябренә кадәр, 2019 елның 25 апреленә кадәр |
| 5. | «Хәрби хезмәткә чакырылучы көне» республика социаль-патриотик акциясен үткәрү | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы | 2018 елның 14 ноябренә кадәр, 2019 елның 19 маена кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең «Казан Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» югары белем бирә торган федераль дәүләт казна хәрби белем бирү учреждениесе (килешү буенча), «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна хәрби белем бирү учреждениесе (килешү буенч), Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | |
| 6. | Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар арасында спортның хәрби-гамәли һәм спорт-техника төрләре буенча Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 74 еллыгына багышланган ярышлар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Региональ оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең «Казан Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» югары белем бирә торган федераль дәүләт казна хәрби белем бирү учреждениесе (килешү буенча), «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна хәрби белем бирү учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча) | |
| 7. | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының муниципаль берәмлекләр буенча бүлекләре вәкилләре (Татарстан Республикасының шәһәрләре һәм районнары, муниципаль), шулай ук Бөек Ватан сугышы, Әфганстандагы сугыш, Төньяк Кавказдагы контртеррористик операцияләр ветераннары белән балалар һәм яшьләрнең очрашуларын үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Региональ оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 8. | Хәрби-патриотик яшүсмерләр клублары һәм «ЮНАРМИЯ» бөтенроссия балалар-үсмерләр хәрби-патриотик | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы, Татар- | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | иҗтимагый хәрәкәте отрядларының республика слетын үткәрү | стан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | |
| 9. | Татарстан Республикасының югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучылар арасында хәрби җыр фестивале | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы каршындагы Яраштыру советы (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| **V. Медицина таныклавы һәм медицина тикшерүе** | | | |
| 1. | Гражданнарны медицина таныклавында катнашучы республика шәһәрләре һәм районнары табиблары-белгечләре белән инструкторлык-методик җыелыш үткәрү | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | с 25.09.2018 елның 25 сентябренә кадәр, 2019 елның 25 мартына кадәр |
| 2. | Гражданнарны башлангыч хәрби исәпкә куйганда медицина таныклавын һәм тикшерүен оештыру һәм үткәрү | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 2019 елның 31 мартына кадәр |
| 3. | Гражданнарны башлангыч хәрби исәпкә куйганнан хәрби хезмәткә чакыру вакытына кадәр тулы күләмдә медицина тикшерүен үткәрү (аның үз вакытында тәгәлләнүен тикшерүдә тотып) | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | 2018 елның 30 декабренә кадәр, 2019 елның 31 марты – 30 декабре |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | **VI. Дәвалау-савыктыру эше** | | |
| 1. | Башлангыч хәрби исәпкә кую нәтиҗәләре буенча 1 – 3 нче исемлекләргә кертелгән, шулай ук хәрби хезмәткә чакыру йомгаклары буенча вакытлыча яраксыз дип танылган 2001 елда туган гражданнар белән дәвалау-савыктыру чараларын үткәрү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының муниципаль берәмлекләр буенча бүлекләре (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 2. | 15 – 16 яшьтәге (2003 – 2004 елда туган) гражданнарны башлангыч хәрби исәпкә куйганга кадәр, профилактика медицина тикшерүләре үткәрү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) | 2019 елның 31 марты – 31 мае |
| 3. | Гражданнарны хәрби хезмәткә чакырганга кадәр, алар белән дәвалау-савыктыру эшләре үткәрүнең нәтиҗәлелеген тикшерүдә тоту | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль орган-нары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | 2018 елның 30 декабренә кадәр, 2019 елның 11 гыйнвары – 29 июле |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 4. | Югары белем бирә торган мәгариф оешмаларында көндезге формада укучыларны һәм укуларын тәмамлаучыларны тикшерүне үткәрү барышын контрольдә тоту | Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы каршындагы тәрбия эше буенча Яраштыру советы (килешү буенча) | 2018 елның 30 декабренә кадәр, 2019 елның 14 июленә кадәр |
| **VII. Гражданнарны хәрби хезмәткә үз ихтыярлары белән әзерләү** | | | |
| 1. | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби һөнәри белем бирү оешмаларына керү өчен кандидатларны сайлап алуны оештыру һәм җибәрү | муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | 2019 елның 1 феврале – 28 апреле |
| 2. | Суворов хәрби училищеларына, хәрби-музыка училищеларына, кадетлар корпусларына, Нахимов хәрби-диңгез училищесына керү өчен кандидатларны туплау һәм җибәрү | муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | 2019 елның 1 феврале – 24 июле |
| 3. | Спортның хәрби-гамәли төрләре буенча клублар, секцияләр, түгәрәкләр эшен оештыру һәм аларның слетларын үткәрү | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасының Региональ оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 4. | Тормыш иминлеге нигезләрен укытучылар – оештыручылар вазыйфаларына югары белем бирә торган мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан запастагы офицерларны сайлап алуны оештыру | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча) | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 5. | Суворов хәрби училищеларына, хәрби-музыка училищеларына, кадетлар корпусларына, Нахимов хәрби-диңгез училищесына керү өчен сайлап алу һәм җибәрү буенча авыр тормыш хәлендә калган ятимнәр һәм балалар белән эшләү | муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | уку елы дәвамында |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 29 август, 736 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы районнарында һәм шәһәрләрендә гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү, аларны чакыруны оештыру һәм үткәрү мәсьәләләре буенча ведомствоара мониторинг төркеме
составы

| | |
|---|---|
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, комиссия рәисе |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча министры, комиссия рәисе урынбасары |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Бородин Александр Ильич | «ЮНАРМИЯ» бөтенроссия балалар-үсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге рәисе (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәр белеме бирү һәм фән бүлеге башлыгы |
| Динниулов Дамир Равил улы | «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» региональ иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Кадыйров Рөстәм Рәиф улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы |
| Погодин Сергей Николаевич | Татарстан Республикасының хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Шакирова Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Юлашев Әхәт Гайнулла улы | «Татарстан Республикасы Сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары (инвалидлары) комитеты» иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча). |

___